# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

«Татарстан Республикасында ветеринария эше турында»
Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм
өстәмәләр кертү хакында

**1 статья.** «Татарстан Республикасында ветеринария эше турында» Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1993, № 6-7) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1. 1 статьяда:

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Татарстан Республикасында ветеринария эше, житештерү ветеринария хезмәте, жирле үзидарәнен ветеринария предприятиеләре, оешмалары, хосусый ветеринария эшчәнлеге белән шөгыльләнүче дәүләтнеке булмаган оешмалар һәм индивидуаль эшкуарлар белән үзара хезмәттәшлектә, Дәүләт ветеринария хезмәте тарафыннан башкарыла.

2. 2 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2 статья. Ветеринария законнары

Ветеринария законнары әлеге Законнан, башка законнардан һәм бүтән норматив хокукый актлардан гыйбарәт.».

3. 3 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3 статья. Ветеринария эшчәнлегенә хокук

Ветеринария эшчәнлеге белән шөгыльләнү хокукына югары яисә урта ветеринария уку йортларын тәмамлаган һәм ветеринария табибы яки ветеринария фельдшеры белгечлеге алган затлар ия булалар.».

4. 4 статьяда:

статьяның исемендә «органнары» сүзеннән соң «,җирле үзидарә органнары» сүзләрен өстәргә;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Татарстан Республикасында ветеринария эшен закон чыгару юлы белән җайга салу Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан гамәлгә ашырыла.»;

3 пунктта:

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

« - терлекчелек фермаларының, комплексларының, терлекчелек продуктларын һәм чималын эшкәртү буенча башка предприятиеләрнең эшчәнлек зонасында әйләнә-тирә мохитнең санитар торышын тикшереп торуны оештыру; терлекләрне инфекцияле авырулардан, массакүләм йогышсыз авырулардан, эпизоотияләрдән кисәтү һәм аларны бетерү чараларын күрү; авырулар һәм үлү нәтиҗәсендә терлекләрнең баш саны кимүгә, терлекчелек продукциясенең сыйфаты начараюга каршы чаралар күрү;»;

бишенче абзацта «аеруча хәтәр» сүзләрен «йогышлы һәм массакүләм йогышсыз» сүзләренә алыштырырга;

түбәндәге редакциядә яңа 4 пунктны өстәргә:

«4. Ветеринария эше өлкәсендә җирле үзидарә органнары карамагына түбәндәгеләр керә:

- авыл хуҗалыгы предприятиеләренең, крестьян (фермер) һәм шәхси ярдәмче хуҗалыкларның терлекләренә ветеринария хезмәте күрсәтүне оештыру мәсьәләләрен карау һәм хәл итү;

- терлекләрнең йогышлы авыруларын профилактикалау һәм бетерү программаларын карау һәм раслау;

165

- авыл хуҗалыгы предприятиеләре, крестьян (фермер) һәм гражданнарның шәхси ярдәмче хуҗалыкларының эшчәнлек зонасында әйләнә-тирә мохитнең санитар торышын тикшереп торуны оештыру;

-терлекләрнең инфекцион, инвазион һәм массакүләм йогышсыз авыруларын кисәтү чараларын күрү;

- терлекләрнең авырулардан үлүен, терлекчелек продуктларының азаюын һәм аларның сыйфаты начараюны киметү чараларын күрү.».

5. II бүлекнең исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«II бүлек.

Дәүләт ветеринария хезмәте. Җитештерү ветеринария хезмәте. Җирле үзидарәнең ветеринария предприятиеләре һәм оешмалары. Хосусый ветеринария эшчәнлеге».

6. 5 статьяда:

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Татарстан Республикасының дәүләт ветеринария хезмәте системасына түбәндәгеләр керә:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе;

Республика ветеринария лабораториясе;

Республика ветеринария станциясе;

республика ветеринария унитар предприятиесе;

төбәк ветеринария лабораторияләре;

районнарның һәм шәһәрләрнең дәүләт ветеринария берләшмәләре.»;

3 пункттагы икенче җөмләне төшереп калдырырга;

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Район ветеринария хезмәтенә дәүләт район (шәһәр) ветеринария берләшмәсе җитәкчелек итә. Дәүләт район (шәһәр) ветеринария берләшмәсе составына түбәндәгеләр керә: терлек авыруларына каршы көрәш станциясе,

ветеринария лабораториясе, ветеринария-санитария экспертизасы лабораторияләре, ветеринария дәваханәләре, ветеринария участоклары һәм пунктлары, ветеринария даруханәләре, шулай ук кошчылык фабрикаларында, терлекчелек продуктларын һәм чималын эшкәртү, саклау предприятиеләрендә дәүләт ветеринария контроле хезмәте.»;

5 пунктны төшереп калдырырга;

5 пунктны 6 пункт дип санарга;

5 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасының Баш ветеринария идарәсе башлыгы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан эш урынына билгеләп куела һәм эш урыныннан азат ителә.»;

5 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Районнарның һәм шәһәрләрнең дәүләт ветеринария берләшмәләре башлыклары эш урыннарына, районнарның һәм шәһәрләрнең администрацияләре белән килешеп, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе башлыгы тарафыннан билгеләп куела һәм эш урыннарыннан азат ителә.».

7. 6 статьяда:

статьяның исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6 статья. Татарстан Республикасы Министрлар кабинетының Баш ветеринария идарәсе вәкаләтләре»;

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсе карамагына түбәндәгеләр керә:»;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Дәүләт ветеринария хезмәтенең барлык учреждениеләре эшчәнлегенә житәкчелек итү.»;

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Җирле үзидарәнең ветеринария предприятиеләре һәм оешмалары, хосусый ветеринария эшчәнлеге белән шөгыльләнүче дәүләтнеке булмаган оешмалар һәм индивидуаль эшкуарлар эшчәнлеген тикшереп тору.»;

2, 3, 4, 5, 6, 7, 8, 9, 10, 11, 12, 13, 14, 15, 16 пунктларны 3, 4, 5, 6, 7, 8, 9, 10, 11, 12, 13, 14, 15, 16, 17 пунктлар дип санарга;

8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Авыл хуҗалыгы һәм башка предприятиеләрдә, оешмаларда һәм крестьян (фермер) хуҗалыкларында ветеринария-дәвалау эшен оештыру һәм гамәлгә ашыру.»;

13 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13. Ветеринария эшчәнлеген лицензияләүне гамәлгә ашыру».

14 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«14. Дәүләт ветеринария күзәтчелеген гамәлгә ашыру.»;

15 пункттагы «бәяләү» сүзен «аттестацияләү» сүзенә алыштырырга;

17 пункттагы «ветеринария мәсьәләләре буенча ...чит ил дәүләтләре» сүзләрен төшереп калдырырга.

8. 7 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7 статья. <u>Житештерү ветеринария хезмәте</u>

Авыл хуҗалыгы, эшкәртү һәм башка предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар үз акчалары исәбеннән җитештерү ветеринария хезмәтен төзи алалар.».

9. Түбәндәге эчтәлекле $7^1$ статьяны өстәргә:

«$7^1$ статья. <u>Җирле үзидарәнең ветеринария предприятиеләре һәм оешмалары</u>

Җирле үзидарә органнары ветеринария предприятиеләре һәм оешмалары төзи алалар. Җирле үзидарә органнары белән алар төзегән

168

ветеринария предприятиеләре һәм оешмалары арасындагы мөнәсәбәтләр законнар нигезендә корыла.».

10. Түбәндәге эчтәлекле $7^2$ статьяны өстәргә:

«$7^2$ статья. Хосусый ветеринария эшчәнлеге

Дәүләти булмаган оешмалар, шулай ук индивидуаль эшкуарлар хосусый ветеринария эшчәнлеге белән шөгыльләнергә мөмкин.».

11. Түбәндәге эчтәлекле $7^3$ статьяны өстәргә:

«$7^3$ статья. Ветеринария эшчәнлеген лицензияләү

Татарстан Республикасы территориясендә ветеринария эшчәнлеге законнар нигезендә лицензияләнергә тиеш.».

12. 8 статьяда:

1 пунктның беренче абзацында «кошларны, балыкларны, умарта кортларын» сүзләрен төшереп калдырырга;

түбәндәге редакциядә яңа 2 пунктны өстәргә:

«2.Дәүләт ветеринария күзәтчелеге объектларына түбәндәгеләр керә:

барлык төр терлекләрнең яшәү һәм аларны асрау урыннары, моңа табигый ирекләге хайваннар да керә;

терлекләрне асрау, сую, терлекчелек продукциясен, генетик материалны, терлек азыгын, аңа кушылмаларны житештерү, әзерләү, саклау, ташу һәм реализацияләү белән шөгыльләнүче милекнең барлык рәвешендәге предприятиеләр һәм оешмалар;

терлекләрне, терлекчелек продукциясен һәм үсемлекчелек продуктларын сата торган базарлар һәм башка оешкан сәүдә урыннары;

хайваннар катнашында массакүләм чаралар үткәрүне гамәлгә ашыручы оешмалар;

биологик калдыкларны саклау, ташу, утильләштерү һәм юкка чыгару урыннары.»;

2 пунктны 3 пункт дип санарга;

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Дәүләт ветеринария күзәтчелеге дәүләт ветеринария инспекциясенең урындагы затлары тарафыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты законнар нигезендә раслый торган Дәүләт ветеринария күзәтчелеге турындагы нигезләмәдә билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.».

13. 9 статьяда:

статьяның исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9 статья. Дәүләт ветеринария инспекторларының хокуклары һәм бурычлары»;

беренче абзацны 1 пункт дип санарга;

1, 2, 3, 4, 5, 6, 7 пунктларны а), б), в), г), д), е), ж) пунктчалары дип санарга;

в) пунктчасында «йогышлы» сүзеннән соң «массакүләм йогышсыз» сүзләрен өстәргә;

ж) пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«ж) ветеринария законнарын бозу турындагы эшләрне карарга һәм билгеләнгән тәртиптә административ җәзалар бирергә;»;

түбәндәге редакциядә яңа з) пунктчасын өстәргә:

«з) Дәүләт ветеринария күзәтчелеге турындагы нигезләмәдә каралган башка вәкаләтләрне гамәлгә ашырырга.»;

түбәндәге редакциядә яңа 2 пунктны өстәргә:

«2. Башка дәүләт ветеринариясе инспекторларының хокуклары һәм бурычлары Дәүләт ветеринария күзәтчелеге турындагы нигезләмә белән билгеләнә.».

14. 10 статьяда:

статьяның исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10 статья. Дәүләт ветеринария күзәтчелеген гамәлгә ашыручы дәүләт ветеринария хезмәтенең урындагы затлары, предприятиеләре, учреждениеләре һәм оешмалары эшчәнлегенең гарантияләре»;

1 пунктта «урындагы затлар» сүзләреннән соң «дәүләт идарәсе органнары вәкилләре булалар, дәүләт яклавында торалар,» сүзләрен өстәргә, «бары тик ... буенча ... гына» сүзләрен төшереп калдырырга;

түбәндәге эчтәлекле 3 пунктны өстәргә:

«3. Дәүләт хакимияте һәм идарәсенең җирле органнары, эшчәнлекләре терлекчелек продуктларын һәм терлек азыгын җитештерүгә, эшкәртүгә, саклауга, ташуга һәм реализацияләүгә бәйле предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар дәүләт ветеринария хезмәте учреждениеләренә һәм оешмаларына (шул исәптән базарлардагы ветеринария-санитария экспертизасы лабораторияләренә, ит комбинатларындагы, кошчылык фабрикаларындагы һәм башка эшкәртү предприятиеләрендәге дәүләт ветеринария контроле хезмәтләренә) файдалануга эш биналарын, кирәкле җиһазны һәм элемтә чараларын түләүсез бирергә, шулай ук алардан файдалану чыгымнарын компенсацияләргә тиешләр.».

15. 11 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11 статья. Җитештерү ветеринария-санитария тикшереп торуы

Терлекчелек азык-төлек продуктларын, материалларын һәм әйберләрен әзерләү һәм аларның әйләнеше буенча эшчәнлекне гамәлгә ашыручы индивидуаль эшкуарлар һәм юридик затлар аларның сыйфатына һәм куркынычсызлыгына, азык-төлек продуктларын, материалларын һәм әйберләрен әзерләү һәм аларнын әйләнеше шартларына ветеринария кагыйдәләре һәм башка норматив һәм техник документлар таләпләренең

171

үтәлешенә җитештерү ветеринария-санитария контролен оештырырга һәм үткәрергә тиеш.».

16. 14 статьяда:

беренче өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасына сәламәт терлекләрне, шулай ук сәламәт терлекләрдән һәм йогышлы авырулар буенча имин территорияләрдән алынган терлекчелек продукциясен кертү рөхсәт ителә.»;

икенче өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасына чит илләрдән терлекләрне, терлекчелек продуктларын кертү башкарма хакимиятнең вәкаләтле федераль органнары тарафыннан федераль законнар нигезендә бирелә торган рөхсәтләр нигезендә гамәлгә ашырыла.»;

түбәндәге эчтәлекле өченче, дүртенче, бишенче яңа өлешләр өстәргә:

«Татарстан Республикасы территориясенә кертелгән терлекләр, терлекчелек продуктлары һәм чимал мәҗбүри тикшерелергә һәм экспертизаланырга тиеш.

Терлекләрнең йогышлы авыруларга, терлекчелек продуктларының һәм чималының сыйфатсызлыгына, агулы химик матдәләр белән зарарлануына нигезле шик туганда продуктларга һәм чималга ветеринария-санитария куркынычсызлыгын раслау өчен пробалар алу, шулай ук өстәмә ветеринария-санитария экспертизасы үткәрелә. Күрсәтелгән продуктлар һәм чимал ветеринария-санитария куркынычсызлыгы турында Татарстан Республикасы Дәүләт ветеринария хезмәте белгечләре бирә торган бәяләмәне алганнан соң гына реализацияләүгә рөхсәт ителә.

Татарстан Республикасы территориясенә чит илләрдән кертелгән хәтәр терлекчелек продуктлары һәм чимал, йогышлы авырулар буенча хәтәр терлекләр федераль законнар нигезендә билгеләнгән тәртиптә кире чыгарылырга яисә конфискацияләнергә тиеш.».

172

17. 15 статьяның икенче өлешендә «шартнамәләр төзү» сүзләрен төшереп калдырырга.

18. 16 статьяның 1 пунктында «башкарма хакимият органнары» сүзләрен «администрацияләр» сүзләренә алыштырырга.

19. 17 статьяда:

статьяның исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«17 статья. Терлек хуҗаларының һәм терлекчелек продукциясен житештерүчеләрнең бурычлары»;

1 пунктны төшереп калдырырга;

2, 3 пунктларны 1, 2 пунктлар дип санарга;

1 пунктта:

алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«терлек авыруларын кисәтүне һәм терлекчелек продуктларының ветеринария-санитария буенча иминлеген тәэмин итүче хуҗалык һәм ветеринария гамәлләре үткәрергә, терлекчелек биналарын һәм терлек азыгын саклау, терлекчелек продуктларын эшкәртү корылмаларын тиешле халәттә тотарга, терлекчелек калдыклары белән әйләнә-тирә табигать мохитен пычратуга юл куймаска тиеш»;

җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«терлекләрне асрауга, терлекчелек продуктларын эшкәртүгә, саклауга һәм реализацияләүгә бәйле объектларны урнаштырганда, төзегәндә, файдалануга тапшырганда зоогигиена һәм ветеринария-санитария таләпләрен үтәргә;»;

сигезенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«ветеринария өлкәсендәге белгечләргә аларның таләпләре буенча тикшереп карау өчен терлекләр бирергә, әлеге белгечләргә терлекләрнең кинәт үлүе яисә ветеринария өлкәсендә берьюлы күпләп авыруы хакында

173

хәбәр итәргә, авыру шиге булган терлекләрне аерып тоту буенча чаралар билгеләргә;»;

тугызынчы, унынчы, унберенче абзацларны төшереп калдырырга;

2 пунктта «һәм алардан файдаланучылар» сүзләрен төшереп калдырырга.

20. 18 статьяда:

статьяның исемен түбәндәгечә бәян итәргә:

«18 статья. Терлекләрне һәм терлекчелек продукциясен тартып алу

беренче өлештә «хуҗаларыннан» сүзен «тартып» сүзенә алыштырырга;

икенче өлештә «хуҗаларыннан» сүзен «тартып» сүзенә алыштырырга.

түбәндәге эчтәлекле өченче, дүртенче, бишенче, алтынчы яңа өлешләрне өстәргә:

«Сыйфатсыз һәм хәтәр терлекчелек продуктларының һәм чималының хуҗасы аларны мөстәкыйль яисә дәүләт ветеринария күзәтчелеге һәм контроле органнары күрсәтмәсе нигезендә әйләнештән чыгарырга тиеш. Әгәр сыйфатсыз һәм хәтәр продуктларның хуҗасы аларны әйләнештән чыгару буенча чаралар күрмәсә, андый продуктлар һәм чимал законнарда билгеләнгән тәртиптә конфискацияләнә.

Әйләнештән чыгарылган сыйфатсыз һәм хәтәр продуктка һәм чималга утильләштерү яисә юкка чыгару мөмкинлеген билгеләү максатларында дәүләт ветеринария күзәтчелеге учреждениеләре тарафыннан ветеринария-санитария экспертизасы уздырылырга тиеш.

Сыйфатсызлык билгеләре аерым ачык булган һәм кешенең гомеренә, сәламәтлегенә турыдан-туры яный торган терлекчелек продуктлары һәм чималы, әгәр аларның хуҗасы килеп чыгышларын раслый алмаса, экспертиза уздырылмыйча утильләштерелергә яисә юкка чыгарылырга тиеш. Мондый продуктларны һәм чималны утильләштергәнче яисә юкка

178

чыгарганчы, аларның хуҗасы дәүләт ветеринария күзәтчелеге вәкиле катнашында аларны алга таба куллану ихтималын бетерә торган теләсә нинди мөмкин һәм ышанычлы ысул белән продуктның һәм чималның үзлеген үзгәртергә тиеш.

Сыйфатсыз һәм хәтәр терлекчелек продуктлары һәм чималы аларга экспертиза үткәрү өчен кирәкле чорга вакытлыча саклауга җибәрелә. Экспертиза нәтиҗәләре буенча дәүләт ветеринария күзәтчелеге учреждениеләре хәтәр продуктларны һәм чималны утильләштерү яисә юкка чыгару буенча карар кабул итәләр.»;

өченче өлешне җиденче өлеш дип санарга, түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Предприятиеләр, оешмалар һәм гражданнар терлекләрне яисә терлекчелек продукциясен тартып алу аркасында үзләренә килгән зыянны законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм шартларда түләттерергә хокуклы.».

21. 20 статьяның икенче өлешендә «Татарстан Республикасының» сүзләрен төшереп калдырырга.

22. 21 статьяда:

исемендә:

«дәүләт санитария-эпидемиология органнарының» сүзләреннән соң «һәм» теркәгечен төшереп калдырып, өтер куярга;

«Татарстан Республикасының Әйләнә-тирә мохитне һәм табигый байлыкларны саклау министрлыгы» сүзләреннән соң «һәм Татарстан Республикасының Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы» дигән сүзләрне өстәргә;

текстында:

«дәүләт санитария-эпидемиология органнарының» сүзләреннән соң «һәм» теркәгечен төшереп калдырып, өтер куярга;

175

«Татарстан Республикасының Әйләнә-тирә мохитне һәм табигый байлыкларны саклау министрлыгы» сүзләреннән соң «һәм Татарстан Республикасының Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы» сүзләрен өстәргә»;

«даими рәвештә тыгыз» сүзләрен төшереп калдырырга; «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан расланган Дәүләт ветеринария күзәтчелеге турында нигезләмәгә таянып,» сүзләрен «законнар нигезендә» сүзләренә алыштырырга.

23. 22 статьяда:

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Татарстан Республикасының республика бюджеты, жирле бюджетлар акчалары һәм шартнамәләр буенча ветеринария эшләрен башкарудан кергән акчалар, шулай ук бюджеттан тыш башка акчалар дәүләт ветеринария хезмәтен финанслау чыганагы булып тора.»;

түбәндәге редакциядә яңа 2 пункт өстәргә:

«2. Җирле үзидарәнең ветеринария предприятиеләрен һәм оешмаларын финанслау җирле үзидарә бюджеты акчалары һәм шартнамәләр буенча ветеринария эшләрен башкарудан кергән акчалар исәбеннән башкарыла.»;

түбәндәге редакциядә яңа 3 пункт өстәргә:

«3. Татарстан Республикасының республика бюджеты, жирле бюджетлар һәм җирле үзидарә бюджетлары акчаларыннан ветеринария гамәлләрен финанслау чыгымнарын планлаштыру финанс чыгымнарының бердәй нормативлары белән башкарыла һәм бюджетларның чыгымнар өлешендә «Ветеринария» дигән аерым бүлекчәсендә карала.»;

2 пунктны 4 пункт дип санарга;

176

3 пунктны 5 пункт дип санарга, «колхозларга, совхозларга, арендачылар оешмаларына, кооперативларга» сүзләрен «авыл хуҗалыгы предприятиеләренә һәм оешмаларына» сүзләренә алыштырырга.

24. 23 статьяда:

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнүче ветеринария учреждениеләрен, авыл хуҗалыгы һәм ветеринария предприятиеләрен, оешмаларын, ветеринария белгечләрен махсус ветеринария мөлкәте белән тәэмин итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе карамагындагы республика ветеринария унитар предприятиесенә йөкләнә.».

түбәндәге редакциядә 3 пункт өстәргә:

«3. Эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнүче ветеринария учреждениеләрен, авыл хуҗалыгы һәм ветеринария предприятиеләрен һәм оешмаларын, ветеринария белгечләрен ветеринария препаратлары, кораллары һәм җиһазлары белән тәэмин итүне законнар нигезендә башка предприятиеләр һәм оешмалар башкарырга мөмкин.».

25. 24 статьяда:

1 пунктта «колхозларда, совхозларда, төрле милек рәвешендәге башка» сүзләрен төшереп калдырырга.

3 пунктта «колхозларга, совхозларга һәм башка» сүзләрен төшереп калдырырга.

26. 25 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«25 статья. <u>Ветеринария законнарын бозган өчен җаваплылык</u>

Индивидуаль эшкуарлар, урындагы затлар, гражданнар һәм юридик затлар ветеринария законнарын бозган өчен законнар нигезендә дисциплинар, административ һәм җинаять җаваплылыгына тартыла.».

27. 26 статьяны төшереп калдырырга.

28. 27 статьяны 26 статья дип санарга.

29. Закон тексты буенча «Министрлар кабинеты» сүзләрен тиешле килешләрдә «Министрлар Кабинеты» дип язарга.

**2 статья.** Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән гамәлгә кертелә.

Татарстан Республикасы
Президенты М.Шәймиев

Казан шәһәре,
2000 елның 14 сентябре
№ 299